ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№17 Кече Урыссу ав. 25 август 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдəниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе, «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында»гы Россия Федерациясе Президентының Указының 29 маддәсе, 2002 елның 25 июлендәге «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында»гы 114-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, Россия Федерациясе халыкларының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүчеләрнең телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясе, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау максатларында, Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге территориясендә милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң закон көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев

Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең 2023 елның “___”__________ _____санлы карарына 1 санлы кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүчеләр милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру турында әлеге Нигезләмә «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау, «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, социаль һәм мәдәни җайлаштыруга, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруда җирле әһәмияттәге мәсьәләне гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

2. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, Ташкичү авыл җирлеге территориясендә милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырганда эшчәнлекнең максатлары түбәндәгеләр:

2.1.1. Милләтара һәм конфессияара конфликтларны кисәтү;

2.1.2. җирлек территориясендә яшәүче халыкларның мәдәни үзенчәлегенә ярдәм итү;

2.1.3. мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итү, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау;

2.1.4. шәхесне һәм җәмгыятьне милләтара (этникара) конфликтлардан яклауны тәэмин итү;

2.1.5 экстремизм күренешләрен профилактикалау һәм мигрантларга карата тискәре мөнәсәбәт;

2.1.5. этникара конфликтлар барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү;

2.1.6. Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче гражданнарның күпмилләтле Россия җәмгыяте кыйммәтләре, мәдәни үзаң, кеше хокукларын һәм ирекләрен үтәү принциплары нигезендә башка милләт һәм дини конфессияләр кешеләренә карата эчке ихтыяҗын булдыру;

2.1.7. яшьләр арасында толерантлык һәм милләтара мәдәният формалаштыру.

2.2. Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырганда, түбәндәгеләр карала:

2.2.1. миграция сәясәте мәсьәләләре буенча халыкка мәгълүмат бирү;

2.2.2милләтара конфликтларны булдырмау чараларын гамәлгә ашыручы хокук саклау органнары эшчәнлегенә ярдәм итү;

2.2.3. башка милләт һәм дини конфессияләр кешеләренә карата толерант тотышны пропагандалау;

2.2.4. балалар һәм яшьләр арасында аңлату эшләре;

2.2.5. милләтара конфликтлар тудыруга катнашы булган затларны ачыклау өчен комплекслы оператив-профилактик чаралар уздыруны тәэмин итү;

2.2.6. инфраструктура объектларында лозунгларның (билгеләрнең) экстремистик юнәлештәге булуына юл куймау.

3. Ташкичү авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре.

3.1. Ташкичү авыл җирлеге депутатлары советы вәкаләтләре:

3.1.1. Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән норматив хокукый актлар кабул итү.

3.1.2. Җирле бюджет чыгымнарын милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Каракашлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга раслау.

3.2. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләре:

3.2.1. Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән муниципаль программаларны эшләү, раслау һәм үтәү;

3.2.2. җирле үзидарә органнары белән муниципальара хезмәттәшлекне, дәүләт хакимияте органнары, хокук саклау органнары, иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне оештыру, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны

профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга;

3.2.3. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы коллегиаль һәм киңәшмә органнарны, шулай ук аларның эшчәнлеген җайга сала торган нигезләмәләрне формалаштыру һәм раслау;

3.2.4. милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, Россия Федерациясе законнары нигезендә милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру механизмы

4.1. Караболак авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү, мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыру, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау буенча шартлар тудыруга юнәлтелгән чараларны планлаштырганда сәяси, хокукый, оештыру, социаль-икътисадый, мәгълүмат һәм башка чаралар комплексы гамәлгә ашырыла:

4.4.1. Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә муниципаль идарәне камилләштерү;

4.4.2. милләтара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, милләтара, динара, этникара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү;

4.4.3. мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыру һәм интеграцияләү өчен шартлар тудыру;

4.4.4. Россия Федерациясенең күпмилләтле халкының (Россия милләтенең) бердәмлеген һәм рухи бердәмлеген ныгыту;

Россия халыкларының этномәдәни күптөрлелеген саклап калу һәм үстерү;

4.4.6. Россиянең социаль-мәдәни өлкәдә милли азчылыкларының хокукларын тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4.4.7. яшь буынны граждан-патриотик тәрбияләү системасын үстерү;

4.4.8. Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү өчен уңайлы шартларны тәэмин итү;

4.4.9 Милләтара (конфессияара) татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү;

4.4.10. Ташкичү авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының дәүләт органнары һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү.

4.2. Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру Ташкичү авыл җирлеге территориясендә милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне мониторинглау, массакүләм мәгълүмат чаралары материалларын анализлау, шулай ук

иҗтимагый, сәяси, дини һәм милли оешмалар белән даими хезмәттәшлек нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.3.Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар түбәндәгеләрне кертәләр:

4.3.1. Массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка мәгълүмат җиткерү, шулай ук администрациянең рәсми сайтында милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән;

4.3.2. халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итү, шулай ук администрациянең рәсми сайтында, гамәлдәге миграция законнары таләпләрен аңлаткан чит ил гражданнары өчен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән;

4.3.3. белем бирү оешмалары белән берлектә аңлату эшләре укучылар арасында милләтче һәм башка экстремистик күренешләр өчен җаваплылык турында, дини һәм милли экстремизмны кисәтү һәм профилактикалау буенча әңгәмәләр үткәрү;

4.3.4. мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыру өчен шартлар тудыру;

4.3.5. Милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, алар белән хезмәттәшлек итү;

4.3.6. Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль программаларында каралган башка чаралар.

5.Финанс белән тәэмин итү

Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру эшчәнлеген финанслау Каракашлы авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.